Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районыУрман Кәләй авыл җирлегенең
Кәләй тимер юл станциясе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы КАРАРЫ

18 ноябрь 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының35 статьясы, 2020елның 12 ноябрендә 09 сәгать00 минутта, 2020 елның 13 ноябрендә09 сәгать00 минутта,2020елның 13ноябрендә 12 сәгать00 минутта, 2020елның 14 ноябрендә 09 сәгать00 минутта, 2020елның 14 ноябрендә 12 сәгать00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге:"Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман - Кәләй авылы җирлеге Кәләй тимер –юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Кәләй тимер –юл станциясе бистәсен су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?»соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1539 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 959 кеше, бу 62% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 851«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның108 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыУрман Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:Кәләй тимер –юл станциясе бистәсен су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетысында бастырырга,Кәләй тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.Н. Фәләхиев